Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Олы Талкыш авылы җирлегенең Олы Талкыш авылы торак пунктында
гражданнар җыены

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Олы Талкыш авыл җирлеге составына керүче Олы Талкыш авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре хакында
КАРАР

2019 елның 24 ноябре № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 25.1, 56 нчы маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасының 35 нче маддәсе нигезендә түбәндәге сорау буенча 2019 елның 24 ноябрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: “Чистай муниципаль районы Олы Талкыш авыл җирлегенең Олы Талкыш авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш, 2020 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау(вак таш сатып алу һәм ташу, грунтлау вак таш җәю).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 267 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 138 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» тавышы өчен халык җыенында катнашкан 138 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Алда язылганнар нигезендә гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Чистай муниципаль районы Олы Талкыш авыл җирлегенең Олы Талкыш авылы торак пунктында гражданнар җыенын булды, гражданнар җыены нәтиҗәләре – гамәлдә дип танырга.

2. “Чистай муниципаль районы Олы Талкыш авыл җирлегенең Олы Талкыш авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш, 2020 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау(вак таш сатып алу һәм ташу, грунтлау вак таш җәю) буенча карар кабул ителде дип санарга.

3. Чистай муниципаль районы Олы Талкыш авыл җирлегенең Олы Талкыш авылы территориясендә Чистай муниципаль районы Олы Талкыш авыл җирлегенең Олы Талкыш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертергә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау(вак таш сатып алу һәм ташу, грунтлау вак таш җәю).

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм игъланнар такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга кирәк.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Талкыш авыл җирлеге башлыгы ________________ Э.Б.Ильин